**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**422613 н.п. им. «25 Октября»**
**тел: 8-(84378) -3-54-22**
**факс: 8-(84378) -3-54-22**

---

**2021 елның 22 ноябре** **71 номер**

## КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлегенең Түбән Кармачы торак пунктында гражданнар җыены карары.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге нең Түбән Кармачы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2022 елда Лаеш муниципаль районының Куюково авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2022 елда үзара салым акчаларын 1500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Түбән Кармачы торак пунктында юлларны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, Түбән Кармачы торак пунктының эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү)

3. Әлеге карарны Александр авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Александр авыл җирлеге нең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: _______ А.И.Каппель**

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш**
**муниципаль районы**
**Александр авыл җирлеге**
**Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы ___________ Ю.Г.Трифонова**